ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 23 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Конституциясенә (2002 елның 19 апрелендәге 1380 номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 9 – 10; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2002, № 3 – 4; 2003, № 9 (I олеш); 2004, № 3 (I олеш); 2005, № 3 (I олеш); 2010, № 3, № 11; 2012, № 6 (I олеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2 бүлек. **Татарстан Республикасы Рәисе**»;

2) 89 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
**«89 статья**

1. Татарстан Республикасы Рәисе дәүләт башлыгы, Татарстан Республикасының иң югары вазыйфаи заты була.
2. Татарстан Республикасының иң югары вазыйфаи заты вазыйфасының исеме – Татарстан Республикасы Рәисе.
3. Татарстан Республикасының иң югары вазыйфаи заты вазыйфасының әлеге статьяның 2 әлешендә каралган исеме Татарстан Республикасы Конституциясенә исемгә карата тиешле таләпне кертә торган үзгәрешләр үз көченә кергәннән соң сайланган Татарстан Республикасының иң югары вазыйфаи затына карата кулланыла.

Татарстан Республикасы Конституциясенә исемгә карата тиешле таләпне кертә торган үзгәрешләр үз көченә кергәнче үткәрелгән сайлаулар нәтиҗәләре буенча вазыйфасына керешкән Татарстан Республикасының иң югары вазыйфаи заты, үз вәкаләтләрен үтәүне туктатканчы, Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә әлеге зат сайланган иң югары вазыйфаи зат вазыйфасы исемен саклап кала.»;

3) 124 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәргә:

«3. Россия Федерациясе Конституциясен үзгәртүгә бәйле рәвештә, шулай ук законлы көченә кергән суд карары нигезендә Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертүгә юнәлдерелгән Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы закон Татарстан Республикасы Конституциясенең 123 статьясы таләпләрен исәпкә алмыйча кабул ителә һәм, аның очен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының билгеләнгән саныннан күпчелеге, кимендә очтән икесе, тавыш бирсә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан кабул ителгән дип санала.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
2. Татарстан Республикасының иң югары вазыйфаи заты вазыйфасының Татарстан Республикасы Конституциясенең 89 статьясындагы 2 өлешендә каралган исеме әлеге Закон үз көченә кергәннән соң сайланган Татарстан Республикасының иң югары вазыйфаи затына карата кулланыла. Әлеге Закон үз көченә кергәнче үткәрелгән сайлаулар нәтиҗәләре буенча вазыйфасына керешкән Татарстан Республикасының иң югары вазыйфаи заты, үз вәкаләтләрен үтәүне туктатканчы, Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә әлеге зат сайланган иң югары вазыйфаи зат вазыйфасы исемен саклап кала.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 31 декабрь
№ 109-ТРЗ